ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 июль 2024 ел

№ 4598

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә законсыз урнаштырылган реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны ачыклау һәм демонтажлау тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы, шәһәр Уставының 9 статьясы, Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре, Башкарма комитетның 2023 елның 20 июлендәге 6462 номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турында нигезләмә, Башкарма комитетның 2024 елның 26 гыйнварындагы 477 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә биналар, төзелмәләр, корылмалар фасадларында мәгълүмати элмә такталар урнаштыруга һәм мәгълүмати элмә такталарны урнаштыру вариантларына карата таләпләр нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә законсыз урнаштырылган реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны ачыклау һәм демонтажлау тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә законсыз урнаштырылган реклама корылмаларын һәм тышкы мәгълүмат чараларын ачыклау һәм демонтажлау тәртибен раслау турында» 2017 елның 31 мартындагы 1733 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан

Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.Ш. Хөснуллинга, Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы Л.И. Әхмәтҗановка, Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы Э.Р. Фәттаховка, Башкарма комитетның административ-техник инспекция идарәсе башлыгы А.З. Хамматовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 15 июлендәге
4598 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә
законсыз урнаштырылган реклама конструкцияләрен һәм
мәгълүмати элмә такталарны ачыклау һәм демонтажлау тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә законсыз урнаштырылган реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны ачыклау һәм демонтажлау тәртибе (алга таба – тәртип), законсыз урнаштырылган реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны ачыклау, реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны демонтажлау турында күрсәтмәләр бирү, реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны демонтажлау тәртибен билгели.

2. Әлеге тәртип «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы, Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре, Башкарма комитетның 2023 елның 20 июлендәге 6462 номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турында нигезләмә, Башкарма комитетның 2024 елның 26 гыйнварындагы 477 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә биналар, төзелмәләр, корылмалар фасадларында мәгълүмати элмә такталар урнаштыруга һәм мәгълүмати элмә такталарны урнаштыру вариантларына карата таләпләр нигезендә эшләнде.

3. Әлеге тәртиптә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

законсыз урнаштырылган реклама конструкциясе – рөхсәтсез урнаштырылган һәм (яки) эксплуатацияләнә торган реклама конструкциясе (алга таба – реклама конструкциясе);

законсыз урнаштырылган мәгълүмати элмә такта (тышкы мәгълүмат чарасы) – элмә такта урнаштыруның дизайн-проектын (тышкы мәгълүмат чарасы паспортын) килештермичә урнаштырылган һәм (яки) эксплуатацияләнә торган мәгълүмати элмә такта (алга таба – мәгълүмати элмә такта).

4. Законсыз урнаштырылган реклама конструкцияләрен, мәгълүмати элмә такталарны ачыклау, законсыз урнаштырылган реклама конструкцияләрен, мәгълүмати элмә такталарны демонтажлау турында күрсәтмәләр бирү һәм законсыз урнаштырылган реклама конструкцияләрен, мәгълүмати элмә такталарны демонтажлау Башкарма комитет карары белән расланган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының вазыйфаи затлары җаваплылыгындагы зоналар Картасына (алга таба - зоналар Картасы) туры китереп, аларның вәкаләләре нигезендә үткәрелә торган, Яр Чаллы шәһәренең тиешле район территориясен яисә зоналар Картасына туры килгән территорияне тикшерү процессында, шулай ук түбәндәгеләр нигезендә, Башкарма комитетның районнар хакимиятләренең вазыйфаи затлары (алга таба – район хакимиятенең вазыйфаи затлары) яисә Башкарма комитетның административ-техник инспекция идарәсенең вазыйфаи затлары (алга таба – АТИИ вазыйфаи затлары) тарафыннан

гамәлгә ашырыла:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетыннан, контроль, күзәтчелек һәм хокук саклау органнарыннан, Яр Чаллы шәһәренең дәүләт хакимияте органнарыннан алынган мәгълүмат;

2) реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны урнаштыру нәтиҗәсендә хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылган гражданнарның, шәхси эшмәкәрләрнең, юридик затларның мөрәҗәгатьләре;

3) массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» челтәреннән алынган мәгълүмат;

4) башка мәгълүмат чыганаклары.

Алынган мәгълүмат, ул район хакимиятенә, АТИИга кергән көннән башлап өч эш көне эчендә, тиешле территорияне тикшерү юлы белән, район хакимиятенең вазыйфаи затлары, АТИИның вазыйфаи затлары тарафыннан тикшерелә.

## 2. Законсыз урнаштырылган реклама конструкцияләрен, мәгълүмати элмә такталарны ачыклау эшен оештыру

5. Районнар хакимиятенең вазыйфаи затлары (АТИИ вазыйфаи затлары) тарафыннан законсыз урнаштырылган реклама конструкцияләре, мәгълүмати элмә такталар ачыкланганда, әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада каралган форма буенча, законсыз урнаштырылган һәм (яки) эксплуатацияләнә торган реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны ачыклау турында акт төзелә.

6. Законсыз урнаштырылган һәм (яки) эксплуатацияләнә торган реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны ачыклау турында акт төзелгән көннән башлап биш эш көне эчендә, район Хакимиятенең вазыйфаи затлары, АТИИ вазыйфаи затлары, әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада каралган форма буенча, законсыз урнаштырылган реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны демонтажлау турында күрсәтмә тапшыруны гамәлгә ашыралар:

- реклама конструкциясенең, мәгълүмати элмә тактаның хуҗасы билгеле булган очракта, расписка һәм (яки) почта аша хат җибәрү юлы белән;

- реклама конструкциясенең, мәгълүмати элмә тактаның хуҗасы билгеле булмаган очракта, реклама конструкциясенең, мәгълүмати элмә тактаның фотографиясен теркәп, демонтажлау турында күрсәтмәне «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән, бу очракта демонтажлау турында күрсәтмә хакында хәбәр итү датасы булып күрсәтмәне шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру датасы тора.

Почта аша җибәрелгән хат кире адрес буенча кайтарылган очракта, район хакимиятенең вазыйфаи затлары, АТИИның вазыйфаи затлары, аны алган вакыттан башлап җиде көн эчендә, реклама конструкциясенең, мәгълүмати элмә тактаның фотографиясен теркәп, законсыз урнаштырылган реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны демонтажлау турында күрсәтмәне «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыралар, бу очракта реклама конструкциясенең, мәгълүмати элмә тактаның хуҗасына демонтажлау турында күрсәтмә хакында хәбәр итү датасы булып демонтажлау турында күрсәтмәне «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру датасы тора.

Законсыз урнаштырылган реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны демонтажлау турында күрсәтмә бирүнең югарыда күрсәтелгән ысулларының теләсә кайсысы яраклы дип санала.

7. Реклама конструкциясенең, мәгълүмати элмә тактаның хуҗасы, законсыз урнаштырылган реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны демонтажлау турында күрсәтмә бирелгән көннән башлап бер ай эчендә, реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны демонтажлауны гамәлгә ашырырга, шулай ук мондый реклама конструкциясендә, мәгълүмати элмә тактада урнаштырылган мәгълүматны күрсәтелгән

күрсәтмә бирелгән көннән башлап өч көн эчендә бетерергә тиеш.

8. Реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта хуҗасы билгеләнгән срокта әлеге тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны демонтажлау бурычын үтәмәсә, район хакимиятенең вазыйфаи затлары, АТИИның вазыйфаи затлары, әлеге тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланган көннән башлап биш эш көне эчендә, 3 нче кушымтада каралган форма буенча, законсыз урнаштырылган реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны демонтажлау турында күрсәтмә үтәлмәү турында акт төзиләр һәм мондый реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта муниципаль мөлкәт объектына яки күпфатирлы йорттагы торак милекчеләренең реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә ризалыгыннан башка мондый милекчеләрнең гомуми мөлкәтенә тоташтырылган очрактан тыш, законсыз урнаштырылган реклама конструкциясен демонтажлау турында күрсәтмәне законсыз урнаштырылган реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта тоташтырылган күчемсез мөлкәт милекчесенә яки башка законлы хуҗасына бирәләр.

Реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта тоташтырылган күчемсез мөлкәт милекчесе яки башка законлы хуҗасы билгеле булган очракта, район хакимиятенең вазыйфаи затлары, АТИИның вазыйфаи затлары законсыз урнаштырылган реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны демонтажлау турында күрсәтмәне, расписка һәм (яки) почта аша хат җибәрү юлы белән, реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта тоташтырылган күчемсез мөлкәт милекчесенә яки башка законлы хуҗасына тапшыруны гамәлгә ашыралар.

Почта аша җибәрелгән хат кире адрес буенча кайтарылган очракта, район хакимиятенең вазыйфаи затлары, АТИИның вазыйфаи затлары, аны алган вакыттан башлап җиде көн эчендә, реклама конструкциясенең, мәгълүмати элмә тактаның фотографиясен теркәп, демонтажлау турында күрсәтмәне «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыралар. Бу очракта реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта тоташтырылган күчемсез мөлкәт милекчесенә яки башка законлы хуҗасына хәбәр итү датасы булып күрсәтмәне «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру датасы тора.

Реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны демонтажлау турында күрсәтмә бирүнең югарыда күрсәтелгән ысулларының теләсә кайсысы яраклы дип санала.

9. Реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта тоташтырылган күчемсез мөлкәт милекчесе яки башка законлы хуҗасы, тиешле күрсәтмә бирелгән, урнаштырылган көннән башлап бер ай эчендә, реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны демонтажларга тиеш. Реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны демонтажлау, саклау яки кирәк очракларда юкка чыгару, реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта тоташтырылган күчемсез мөлкәт милекчесе яки башка законлы хуҗасы хисабына гамәлгә ашырыла. Әлеге күчемсез мөлкәт милекчесенең яки башка законлы хуҗасының таләбе буенча, реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта хуҗасы реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны демонтажлауга, саклауга яки кирәк очракларда юкка чыгаруга бәйле тотылган кирәкле чыгымнарны бу милекчегә яки әлеге законлы хуҗага кайтарырга тиеш.

10. Әгәр реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта тоташтырылган күчемсез мөлкәт милекчесе яки башка законлы хуҗасы, әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны демонтажлау буенча бурычын билгеләнгән срокта үтәмәсә, район хакимиятенең вазыйфаи затлары, АТИИның вазыйфаи затлары, әлеге тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән срок чыккан көннән башлап биш эш көне эчендә, 3 нче кушымтада каралган форма буенча, законсыз урнаштырылган реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны демонтажлау турында күрсәтмә үтәлмәү турында акт төзиләр. Бу очракта яки әлеге күчемсез мөлкәт

милекчесе яки башка законлы хуҗасы билгеле булмаган очракта, реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны демонтажлау, аны саклау яки кирәк очракларда юкка чыгару шәһәр бюджеты акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.

11. Әгәр реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта муниципаль мөлкәт объектына тоташтырылган булса, әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән очракта аны демонтажлау, саклау яки кирәк очракларда юкка чыгару шәһәр бюджеты акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.

12. Әгәр реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта күпфатирлы йорттагы торак милекчеләренең реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә ризалыгыннан башка мондый милекчеләрнең гомуми мөлкәтенә тоташтырылган булса, әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән очракта аны демонтажлау, саклау яки кирәк очракларда юкка чыгару, күпфатирлы йорттагы торак милекчеләре тарафыннан сайланган күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулы нигезендә, күпфатирлы йортның идарәче компаниясе, торак милекчеләре ширкәте, торак кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 3. Законсыз урнаштырылган реклама конструкцияләрен, мәгълүмати элмә такталарны демонтажлау һәм күчерү тәртибе

13. Законсыз урнаштырылган реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны демонтажлау буенча бурычны үтәү өчен билгеләнгән срок чыкканнан соң, 7, 9 пунктларда күрсәтелгән очракларда, район хакимиятенең вазыйфаи затлары, АТИИның вазыйфаи затлары Башкарма комитетның демонтажланырга тиешле реклама конструкцияләре, мәгълүмати элмә такталар исемлеген раслау турында карар проектын әзерлиләр.

14. Башкарма комитетның демонтажланырга тиешле реклама конструкцияләре, мәгълүмати элмә такталар исемлеген раслау турында карарында түбәндәгеләр күрсәтелергә тиеш:

- демонтажланырга тиешле реклама конструкцияләре, мәгълүмати элмә такталар исемлеге;
- кадастр номеры (булган очракта) һәм адрес ориентирлары күрсәтелгән реклама конструкцияләрен, мәгълүмати элмә такталарны урнаштыру урыны;
- реклама конструкцияләрен, мәгълүмати элмә такталарны демонтажлау нигезләре;
- реклама конструкцияләрен, мәгълүмати элмә такталарны күчерү урыны (күчерү турында карар кабул ителгәндә).

15. Башкарма комитетның демонтажланырга тиешле реклама конструкцияләре, мәгълүмати элмә такталар исемлеген раслау турында карары нигезендә, демонтажланырга тиешле реклама конструкцияләрен, мәгълүмати элмә такталарны мәҗбүри демонтажлау буенча эшләрне оештыруны, махсуслаштырылган оешманы җәлеп итеп, район хакимиятендә төзелгән демонтажлау комиссиясе, АТИИның вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашыра.

Демонтажлау комиссиясенең персональ составы һәм аның нигезләмәсе тиешле район хакимияте тарафыннан раслана.

16. Реклама конструкцияләрен, мәгълүмати элмә такталарны демонтажлау, чыгару һәм саклау эшләрен гамәлгә ашыру буенча махсуслаштырылган оешманы билгеләү, гамәлдәге законнар таләпләре нигезендә, район хакимияте, АТИИның вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

17. Мәҗбүри демонтажлау шәһәр бюджеты акчалары хисабына гамәлгә ашырыла, тотылган чыгымнар алга таба реклама конструкцияләре, мәгълүмати элмә такталар хуҗасы хисабына компенсацияләнә.

18. Демонтажлау барышында демонтажлау комиссиясе тарафыннан, әлеге нигезләмәгә 4 нче кушымтада каралган форма буенча демонтажлау турында акт (алга

таба – демонтажлау турында акт) төзелә.

Актта теркәлгән объектның габаритлары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 21 декабрендәге 2200 номерлы карары белән расланган Автомобиль транспортында йөкләр ташу кагыйдәләрендә (алга таба – Кагыйдә) билгеләнгән транспорт чараларының рөхсәт ителгән иң чик габаритларыннан арткан һәм Кагыйдәләрдә билгеләнгән эре габаритлы йөк критерийларына туры килгән очракта, объект демонтажланган хәлдә чыгарылырга тиеш.

19. Демонтажлау хакимият яки АТИИ вәкиле катнашында башкарыла. Җәмәгать тәртибен саклау максатында, демонтажлау комиссиясенең соравы буенча, демонтажлау урынына хокук саклау органнары хезмәткәрләре чакырыла. Хокук саклау органнары хезмәткәрләренең килмәве демонтажлау өчен каршылык булып тормый.

20. Демонстажлау (сүтү) ысулын сайлау һәм алга таба күчерү җаваплылыгы махсуслаштырылган оешмага йөкләнә. Демонтажлауны үткәргәндә реклама конструкцияләренә, мәгълүмати элмә такталарга зыян килү мөмкинлегенә максималь дәрәҗәдә юл куелмаска тиеш. Әгәр махсуслаштырылган оешма вәкиле фикеренчә, реклама конструкцияләрен, мәгълүмати элмә такталарны сүтмичә демонтажлау мөмкин булмаса, демонтажлау комиссиясе тарафыннан демонтажлау турындагы актта бу хакта билгеләп куела.

21. Демонтажлау турында актта демонтажлау комиссиясе, махсуслаштырылган оешма һәм башка затлар тарафыннан демонтажлау вакытында башкарыла торган барлык гамәлләр, реклама конструкцияләренең, мәгълүмати элмә такталарның тасвирламалары һәм характеристикалары теркәлә, реклама конструкциясенең, мәгълүмати элмә тактаның демонтажлау эшләре башланганчы һәм алар тәмамланганнан соң техник торышы тасвирлана, шулай ук демонтажлауны үткәрә торган махсуслаштырылган оешма хезмәткәрләренең фамилияләре, исемнәре һәм аталарының исемнәре күрсәтелә. Демонтажлау вакытында гамәлгә ашырыла торган фото- һәм видеофиксация материаллары, тиешле кушымталар рәвешендә, демонтажлау турындагы актның аерылгысыз өлеше булып тора. Демонтажлау турында төзелгән акт барлык катнашучы затлар тарафыннан имзалана. Демонтажлау турында акт 2 нөсхәдә төзелә, шуларның берсе - махсуслаштырылган оешмага, икенчесе – район хакимиятенең демонтажлау комиссиясенә, АТИИга тапшырыла.

22. Демонтажлау, транспортлау буенча эшләрне, шулай ук төяү-бушату эшләрен тиешенчә үтәмәү нәтиҗәсендә реклама конструкцияләре, мәгълүмати элмә такталар хуҗасына китерелгән югалту, җитмәгән өлеш яки зыян өчен махсуслаштырылган оешма җаваплы.

23. Демонтажлауны гамәлгә ашырган көнннән соң килә торган өч эш көненнән дә соңга калмыйча, район хакимиятенең вазыйфаи затлары, АТИИның вазыйфаи затлары реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә тактасы хуҗасына, демонтажланган реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта тоташтырылган күчемсез мөлкәт милекчесенә яки башка законлы хуҗасына башкарылган демонтаж турында белдерү кәгазе җибәрәләр. Реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта хуҗасы ачыкланмаган очракта, шулай ук реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта тоташтырыла торган күчемсез мөлкәт милекчесе яки башка законлы хуҗасы билгесез булса, район хакимиятенең вазыйфаи затлары, АТИИның вазыйфаи затлары өч эш көне эчендә, «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында демонтажлау турында хәбәр урнаштыралар.

24. Башкарылган демонтаж турында хәбәр урнаштырылган датадан башлап җиде көн эчендә реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта хуҗасы, реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта тоташтырылган күчемсез мөлкәт милекчесе яки башка законлы хуҗасы тарафыннан демонтажланган реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта сорап алынмаган очракта, реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә хуҗасыз дип

танылырга тиеш.

25. Реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны мәҗбүри демонтажлау гамәлгә ашырылган очракта, реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта хуҗасы яисә реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта тоташтырылган күчемсез мөлкәт милекчесе яки башка законлы хуҗасы реклама конструкциясен, Башкарма комитет тарафыннан мәгълүмати элмә тактаны демонтажлауга, транспортлауга һәм саклауга бәйле тотылган чыгымнарны капларга тиеш.

26. Демонтажланган реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны демонтажлау, транспортлау һәм саклау өчен чыгымнарны каплауны исәпләү, махсуслаштырылган оешма тарафыннан реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны демонтажлау, транспортлау һәм саклау эшләре өчен түләгәндә, Башкарма комитет тарафыннан тотылган факттагы чыгымнар буенча башкарыла.

27. Тиешле күрсәтмәне алган (тиешле күрсәтмә бастырып чыгарылган) көннән башлап яки реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта демонтажланган көннән башлап өч ай эчендә, реклама конструкциясен демонтажлау турында күрсәтмә, мәгълүмати элмә тактаны демонтажлау турында күрсәтмә бирү турында карар, реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны демонтажлау буенча судка яки арбитраж судка шикаять бирелергә мөмкин.

## 4. Реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны саклауны һәм кире кайтаруны тәэмин итү

28. Реклама конструкцияләре һәм мәгълүмати элмә такталар хуҗасы, саклауда булган реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны (аларны тәшкил итүче элементларны) аңа кире кайтару максатында, гариза белән Башкарма комитетка мөрәҗәгать итә.

Гаризага реклама конструкцияләренең һәм мәгълүмати элмә такталарның хокук иясенә каравын раслый торган документларны, реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны демонтажлауга, күчерүгә һәм саклауга бәйле чыгымнар өчен түләүне раслый торган документларны терки.

29. Реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны кире кайтару, реклама конструкцияләре һәм мәгълүмати элмә такталар хуҗасы тарафыннан Тәртипнең 28 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыру шарты белән, кабул итү-тапшыру акты, мөлкәт исемлеге һәм фото- һәм (яки) видеофиксация материаллары нигезендә, район хакимиятенең демонтажлау комиссиясе, АТИИ тарафыннан башкарыла.

30. Реклама конструкцияләре һәм мәгълүмати элмә такталар хуҗасы, реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны вакытлыча саклау мәйданчыгына күчергән вакыттан башлап 3 ай эчендә, объектны кире кайтару өчен мөрәҗәгать итмәгән очракта, алга таба Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган тәртиптә утильләштерү өчен, Башкарма комитет реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны хуҗасыз дип тану һәм әлеге реклама конструкцияләренә һәм мәгълүмати элмә такталарга муниципаль милек хокукын тану турында гариза белән судка мөрәҗәгать итә.

Реклама конструкцияләре һәм мәгълүмати элмә такталар бәясе өч мең сумнан түбән булганда, шулай ук реклама конструкцияләре һәм мәгълүмати элмә такталар хуҗасы Башкарма комитет файдасына аларга ия булу хокукларыннан язмача баш тарткан очракта, суд карары таләп ителми.

31. Реклама конструкцияләре һәм мәгълүмати элмә такталар хуҗасы реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны демонтажлау, күчерү һәм саклау чыгымнарын компенсацияләүдән баш тарткан очракта яки тиешле таләпләр күрсәтелгән вакыттан башлап бер ай эчендә компенсация суммасын түләмәгән очракта, Башкарма комитет реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны демонтажлау,

күчерү һәм саклау чыгымнарын каплау турындагы таләпләр белән судка мөрәҗәгать итә.

32. Реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны утильләштерүне, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына, объектларны утильләштерү эшләрен башкаруга контракт яки шартнамә буенча вәкаләтле оешма тәэмин итә.

33. Демонтажлауга, күчерүгә, саклауга бәйле рәвештә махсуслаштырылган оешма тарафыннан тотылган, реклама конструкцияләре һәм мәгълүмати элмә такталар хуҗасыннан алына торган акчалар шәһәр бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

34. Объектларны демонтажлау нәтиҗәсендә барлыкка килгән бәхәсләр Россия Федерациясе законнары нигезендә хәл ителә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә законсыз урнаштырылган реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны ачыклау һәм демонтажлау тәртибенә
1 нче кушымта

Законсыз урнаштырылган реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны ачыклау турында
АКТ

№ _________ «___»__________ 202__ ел

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(район хакимияте вәкилләренең Ф.И.А.и., вазыйфасы)

түбәндәгеләр турында әлеге актны төзеделәр:
______________________________________________________________ адресы буенча
(реклама конструкциясенең һәм мәгълүмати элмә тактаның адресы һәм урнашу урыны)

Реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта ачыкланды:
______________________________________________________________________________
(реклама конструкциясенең, мәгълүмати элмә тактаның тибы)

реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта тасвирламасы:
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________.

Объектның кемгә каравы турында мәгълүмат ______________________________________
______________________________________________________________________________
(юридик яки физик зат (ШЭ) мәгълүматлары, адресы)
______________________________________________________________________________
(күрсәтелә: реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта законлы (законсыз) урнаштырылган

Урнаштыру хокукына документлар юк:
______________________________________________________________________________
(реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны урнаштыру хокукы бирә торган документлар булмау яисә мондый документларның гамәлдә булу срогы тәмамлану турында мәгълүмат кәрсәтелә)

Акт реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта хуҗасы (вәкаләтле вәкил) катнашында төзелде:
______________________________________________________________________________
(реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта хуҗасының (вәкаләтле вәкиленең) Ф.И.А.и. (Имза)
______________________________________________________________________________
(реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта хуҗасы (вәкаләтле вәкил) имзалаудан баш тарткан очракта, тиешле язма ясала)

Район хакимияте, АТИИ вәкилләренең имзалары ______________________________.

Кушымта: урнаштырылган һәм (яки) файдаланыла торган реклама конструкциясе(-ләре), мәгълүмати элмә такта(-лар) адресы, урнаштырылган һәм (яки) файдаланыла торган реклама конструкциясенең(-ләренең), мәгълүмати элмә тактаның(-ларның) төре, тибы, Яр Чаллы шәһәре территориясендә реклама конструкциясен(-ләрен) урнаштыру схемасындагы № (булганда) күрсәтелгән һәм фотода реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта билгеләнгән фотоматериал _______ биттә ______ нөсхәдә.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә законсыз урнаштырылган реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны ачыклау һәм демонтажлау тәртибенә
2 нче кушымта

Законсыз урнаштырылган реклама конструкциясен,
мәгълүмати элмә тактаны демонтажлау турында
КҮРСӘТМӘ

№ ________ «___»__________ 202__ ел

Кемгә: ______________________________________________________________
(гражданның (ШЭ) Ф.И. А.и. яисә юридик затның исеме һәм адресы)
түбәндәге вакыттан соң бер ай эчендә _________________________________________
_____________________________________________________________________
(күрсәтелә: әлеге күрсәтмәне кулга, почта аша тапшыру һәм «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыру)

_____________________________________________________________________

Сезгә ирекле тәртиптә үз көчегез белән һәм үз хисабыгызга _______________________________________________ адресы буенча урнаштырылган законсыз урнаштырылган реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны _____________________________________________________________ демонтажларга кирәк, шулай ук әлеге күрсәтмә бирелгән көннән башлап өч көн эчендә, реклама конструкциясендә, мәгълүмати элмә тактада урнаштырылган мәгълүматны бетерергә, реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта законсыз урнаштырылган булган реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта урнаштырылган урынны баштагы хәленә китерергә.
Әлеге күрсәтмә үтәлмәгән очракта, реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта мәҗбүри рәвештә демонтажланачак.
Күрсәтмә белән таныштырылды _____________________________________________.
(вазыйфаи затның имзасы, имзаның расшифровкасы)
Күрсәтмәдә күрсәтелә:
1) күрсәтмә алудан һәм аның белән танышу турында имза куюдан түбәндәге сәбәп буенча (сәбәпләрен аңлатмыйча) ______________________ баш тартты;
2) күрсәтмәне җибәрү ысулы ___________________________________;
3) реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны законсыз урнаштыруны гамәлгә ашырган зат билгеләнмәгән
_____________________________________________________________________;
4) күрсәтмә урнаштырылган __________________________________________________
_____________________________________________________________________
(район хакимияте, АТИИ вәкиленең имзасы (имзаның расшифровкасы)
_____________________________________________________________________
(вәкаләтле органның адресы, элемтә телефоны)

Башкарма комитетның
________________________________ районы хакимияте Башлыгы

_____________________________________________________________________

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә законсыз урнаштырылган реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны ачыклау һәм демонтажлау тәртибенә
3 нче кушымта

Законсыз урнаштырылган реклама конструкциясен,
мәгълүмати элмә тактаны демонтажлау турында күрсәтмәне үтәмәү турында
АКТ

№ ___________ «___»_________ 202__ ел

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

(Хакимият, АТИИ вәкиленең Ф.И.А.и., вазыйфасы _______________________)

Түбәндәгеләр турында әлеге актны төзеделәр:

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

(түбәндәге адрес буенча буенча реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны законсыз урнаштыруны гамәлгә ашырган (юридик яки физик зат (ШЭ) мәгълүматлары, адресы):

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

(күрсәтелә: законсыз урнаштырылган реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны демонтажлау турында «__» _______ 202___ елгы № ______ күрсәтмәне үтәде (үтәмәде)

_______________________________________________________________________________

(күрсәтелә: реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта демонтажланган (демонтажланмаган), чыгарылган (чыгарылмаган)

Кушымта:

- законсыз урнаштырылган реклама конструкциясенең, мәгълүмати элмә тактаның фотографиясе (реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта урнаштырылган урын).

Район хакимияте, АТИИ вәкилләренең имзасы:

______________________________

______________________________

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә законсыз урнаштырылган реклама конструкцияләрен һәм мәгълүмати элмә такталарны ачыклау һәм демонтажлау тәртибенә
4 нче кушымта

Законсыз урнаштырылган реклама конструкциясен,
мәгълүмати элмә тактаны демонтажлау турында
АКТ

№ __________ «___»_________ 202__ ел

Демонтажлауны (сүтүне) башлау: _________ сәгать ________ мин.
Демонстажлауны (сүтүне) тәмамлау _____________ сәгать __________ мин.
_______________________ районының демонтажлау комиссиясе (АТИИның вазыйфаи затлары) ________________________________________________________________
түбәндәгеләр катнашында
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
(Ф.И.А.и., вазыйфасы)
түбәндәге адрес буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә законсыз урнаштырылган реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны мәҗбүри демонтажлауны гамәлгә ашырдылар:
________________________________________________________________________________,
(реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта урнашкан урын адресы)
кемгә караган ____________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
(юридик яки физик зат (ШЭ) мәгълүматлары, адресы)

Демонтажлау законсыз урнаштырылган реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны демонтажлау турында күрсәтмәне үтәмәү турында «___» _____ 202__ елгы № _____ акт белән расланган «___» _____ 202__ елгы № _____ күрсәтмәне үтәмәү нигезендә башкарылды.

Визуаль тикшерү нигезендә, демонтажлау вакытына реклама конструкциясенең, мәгълүмати элмә тактаның тышкы торышы
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

Реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны сүтү башкарылмаган (башкарылган) (кирәклесенең астына сызарга).

Реклама конструкциясен, мәгълүмати элмә тактаны сүтмичә, аны демонтажлау (сүтү) мөмкин булмау сәбәпләре:
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

Мәҗбүри демонтажланган реклама конструкциясе, мәгълүмати элмә такта түбәндәге адрес буенча җаваплы саклауга тапшырылды:

______________________________________________________________________________.

Оешма вәкиле: _____________________________________

(Ф.И.А.и., вазыйфасы, имза)

_______________ районының демонтажлау комиссиясе әгъзалары, АТИИның вазыйфаи затлары:

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(Ф.И.А.и., вазыйфасы, имза)

Шаһитлар:

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

(Ф.И.А.и., паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны, имза)

Акт белән таныштырылды (таныштырылмады)

______________________________________________________________________________

(юридик яки физик зат (ШЭ) мәгълүматлары, имза)

Имзалаудан баш тартты ________________________________________________

(______ районы демонтажлау комиссиясе әгъзаларының, АТИИ вазыйфаи затларының Ф.И.А.и.)